**ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА, АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ**
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ**
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе)

# БОЕРЫК

07.09.2015 № 12-07 / 57

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, аның әйләнеше һәм сыйфатын дәүләт контролендә тоту һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 14 маендагы 341 номерлы карары һәм Министрлар Кабинетының 2015 елның 5 сентябрендәге 643 номерлы «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында Иҗтимагый совет турында типик нигезләмәгә үгәрешләр кертү турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында Иҗтимагый совет турында» карары белән расланган үзгәрешләр кертелү сәбәпле б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, аның әйләнеше һәм сыйфатын дәүләт контролендә тоту һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында 2015 елның 22 апрелендәге 212-07/19 номерлы «Иҗтимагый Совет турында Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, аның әйләнеше һәм сыйфатын дәүләт контролендә тоту һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе боерыгы белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, аның әйләнеше һәм сыйфатына дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау

буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет (алга таба - Иҗтимагый совет), Татарстан Республикасында алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары карамагына кертелгән вәкаләтләр чикләрендә Дәүләт контролен тәэмин итү буенча дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда, шулай ук кулланучылар базарында (алга таба — Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эшчәнлек өлкәсе) хокук бозуларны кисәтү һәм булдырмауга юнәлтелгән чараларны тормышка ашыру өлкәсендә гражданнарның һәм җәмәгать берләшмәләренең һәм башка дәүләтнеке булмаган оешмаларның хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә (алга таба - Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эшчәнлек өлкәсе), этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, аның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясе каршындагы киңәшмә органы (Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе) булып тора.»;

2.1 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе» сүзләрен төшереп калдырырга; «иҗтимагый берләшмәләр» сүзләреннән соң текстны «һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерцияле булмаган оешмалар» сүзләре белән тулыландырырга; 3.1 пунктта «социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук дәүләтнеке булмаган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга; 3.2 пунктта «12» санын «5» санына алмаштырырга; 3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Иҗтимагый совет составына иҗтимагый оешмалар һәм башка социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре булган гражданнар да керә ала. Шул ук вакытта аларның һөнәри сыйфатлары, шул исәптән тиешле белемнәре, бу өлкәдә эш тәҗрибәсе, Иҗтимагый совет алдында куелган мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен кирәкле мәсьәләләр исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән бергә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән затлар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысын тәшкил итүче санда кертелә»;

3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Иҗтимагый совет әгъзалары булып Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, суд карары нигезендә эшкә яраксыз дип танылган затлар, сүнмәгән яки хөкем ителгән затлар, шулай ук

башка затлар тора алмый, алар «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмый.»; 3.5 пунктының икенче абзацында «башкарыла» сүзен «карала» сүзе белән алмаштырырга;

3.6 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәрг:

«аны Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Россия Федерациясенең башка субъектлары вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куюлар;»; 3.8 пунктның дүртенче абзацында «кандидат вазыйфасына» сүзләрен төшереп калдырырга. 4.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башкарма орган инициативасы буенча үткәрелә торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, «түгәрәк өстәлләрдә» һ. б.), дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлардан, персональ мәгълүматлар турында белешмәләрдән һәм мөмкинлекләре чикләнгән мәгълүматлардан файдаланып, федераль законнар нигезендә керү мөмкинлеге чикләнә торган чаралардан тыш, катнашырга;»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе инициативасы белән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан эшләнгән, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан эшләнелгән норматив хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә каралган, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет утырышларында алдан фикер алышудан башка кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар проектларына Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү максатларында үткәрелә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.03.2013 елның 2214 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнелә торган, башкарма хакимиятнең бу органнары каршындагы Иҗтимагый совет утырышларында алдан фикер алышудан башка кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәлүгә җибәрелә торган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында.»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе инициативасы белән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан эшләнгән, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан эшләнелгән норматив хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә каралган, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет утырышларында алдан фикер алышудан башка кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар проектларына Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү максатларында үткәрелә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.03.2013 елның 2214 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнелә торган, башкарма хакимиятнең бу органнары каршындагы Иҗтимагый совет утырышларында алдан фикер алышудан башка кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар составын раслау турында һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәлүгә җибәрелә торган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Иҗтимагый совет утырышлары, әгәр аларда Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Иҗтимагый совет әгъзасы, утырышта шәхси катнашу мөмкинлеге булмаганда, Иҗтимагый советның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышларын һәм фикерләрен Иҗтимагый советның башка әгъзасына язмача, факсимиль яки электрон почта аша, бу хакта алдан ук рәискә, яисә Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына, яисә җаваплы секретаренә җиткерергә хокуклы. Утырышта катнашучылар арасында.

Иҗтимагый совет тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар (норматив хокукый актлар) проектларын карау аларны Министрлык, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы ведомствосы тарафыннан Иҗтимагый советка җибәргәннән соң ун календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатларында тавыш бирүне уздыру Иҗтимагый советның барлык әгъзаларын сораштыру нәтиҗәләрен Иҗтимагый совет рәисе имзалаган беркетмәгә кертеп, читтән торып тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин. Мондый тавыш бирү почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яки башка элемтә чаралары, тапшырыла торган һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең аутентиклыгын һәм аларны документаль раслауны тәэмин итә торган документлар белән алмашу юлы белән үткәрелергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирү үткәрелгән очракта, рәис урынбасарына, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына тәкъдим ителә торган көн тәртибе, норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) җибәрелә, аның буенча Иҗтимагый совет бәяләмәсен үткәрү датасына кадәр җиде календарь көннән дә соңга калмыйча

бирергә кирәк. Иҗтимагый совет әгъзалары, кирәк булганда, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясеннән норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча өстәмә материаллар һәм мәгълүмат соратып алалар.

Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.»;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе сайтының «Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет» бүлегендә урнаштырыла.».

2. Әлеге Боерыкның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Җитәкче И.А. Марченко